| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 12 ноябре № 11

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Михайловка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 21 ноябрендәге 909 номерлы карары (25.11.2024 №1049 редакциясендә)белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы белән, Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Михайловка торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 30 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Михайловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Ивановка авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, контракт буенча мобилизацияләнгән һәм хәрби хезмәткәрләрдән, күпбалалы гаиләләрдән тыш, 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Михайловка авылында Үзәк, Югары урамнары буенча юлларны кардан чистарту); 2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Михайловка авылында гомуми файдаланудагы территорияләрдә кулдан үлән чабу хезмәтләре күрсәтү, триммер өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу); 3) ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү

(Михайловка авылындагы муниципаль зиратта авария хәлендәге агачларны санитар кисү һәм кисү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек ур., 5 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Бодряева